# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Камышлы торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**11 ноябрь 2020 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге Камышлы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Камышлы авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Камышлы торак пунктында Молодежная урамы буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (вак таш җәелгән юлларны карап тоту, юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Камышлы торак пунктында җирлекне яктырту һәм урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урнаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр күрсәтү);
- Камышлы торак пунктында күмү урыннарны карап тоту (дератизация, тоташ гербицид белән химик эшкәртү, агач кисү, куакларны кисү, үлән чабу, чүп-чар җыю, хуҗалык инвентаре, инструментлар һәм җиһазлар сатып алу).
- Камышлы торак пунктында тракторчыга карны механикалаштырылган җыю буенча хезмәт күрсәтүгә түләү (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләү;
- Камышлы торак пунктында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне»нә бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү, сәхнә костюмнары, музыка аппаратурасы сатып алу).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Чалпы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге башлыгы _____________ А.М.Мөхәмәтшин